ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«04» август 2022 ел

№ 837

«Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 907 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 7 сентябрендәге 907 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 907 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»

2.2. 12 пунктка түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– беренче абзацта «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

– икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми санының нисбәте белән характерлана торган ташламалардан түләүчеләрнең ихтыяҗы»;

2.3. 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4. 19 пунктны естәргә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Салым чыгымнары кураторы кирәк булганда Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре салым чыгымының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин»;

2.5. 20 пунктны өстәргә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендәге салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне

Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендәге техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рехсәт ителә».

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 07.09.2021г. № 907 номерлы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 22 июлендәге 783 номерлы карарын гамәлдән чыккан диеп санарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин